# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТУРАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ТУРАЙ АВЫЛЫНДА 2024 ЕЛДА ГРАЖДАННАРНЫҢ ҮЗАРА САЛЫМЫН КЕРТҮ ТУРЫНДА ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ НӘТИҖӘЛӘРЕ ХАКЫНДА

«29» ноябрь 2023 ел № 110

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге Уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге Советының 2019 елның 4 октябрендәге 100 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыеннарын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» карары нигезендә, 2023 елның 28 ноябрендә 16.00 сәг.Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Турай авылында гражданнар җыенында «2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлегенең Турай авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларга тиңләштерелгәннәрдән, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, ә күп балалы гаиләләрдән 50% ка киметеп 500 сум күләмендә билгеләргә, махсус хәрби операциядә катнашучыларны түләүдән азат итәргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы?” дигән сорау каралды һәм йомгаклау беркетмәсе төзелде

1. Турай авылында урам яктырткычлары урнаштыру.-7 данә
2. Су насосын сатып алу -2 данә
3. Триммер сатып алу.
4. Үлән чабу, ягулык-майлау материаллары һәм хезмәт хакы
5. Чылбырлы пычкы сатып алу
6. Турай авылы зираты территориясендә агачларны кисү
7. Спорт мәйданчыгы өчен материал сатып алу һәм койма (койма) урнаштыру
8. Турай авылында кышкы чорда карны чистарту.
9. Совет һәм Мәктәп урамнарында 2 данә янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру
10. Яңа су башнясына койма урнаштыру.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 300 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 205 граждан.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"ӘЙЕ" - 164 граждан тавыш бирде;

"ЮК" - 41 граждан

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР КЫЛДЫ**:

1. Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлегенең Турай авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, җыен нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. 2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлегенең Турай авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларга тиңләштерелгәннәрдән, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, ә күп балалы гаиләләрдән 50% ка киметеп 500 сум күләмендә билгеләргә, махсус хәрби операциядә катнашучыларны түләүдән азат итәргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы?" дигән сорауга карар кабул ителде.

   1. Турай авылында урам яктырткычлары урнаштыру.-7 данә
   2. Су насосын сатып алу -2 данә
   3. Триммер сатып алу.
   4. Үлән чабу, ягулык-майлау материаллары һәм хезмәт хакы
   5. Чылбырлы пычкы сатып алу
   6. Турай авылы зираты территориясендә агачларны кисү
   7. Спорт мәйданчыгы өчен материал сатып алу һәм койма (койма) урнаштыру
   8. Турай авылында кышкы чорда карны чистарту.
   9. Совет һәм Мәктәп урамнарында 2 данә янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру
   10. Яңа су башнясына койма урнаштыру.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында « Турай авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы

Турай авыл җирлеге башлыгы Г.Б. Куляшова